**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

_____________                                        № ______

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының
социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү һәм торак урыны мәйданының хисап нормасы турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 50,58 статьяларын һәм дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу максатларында, торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе, гаиләнең бер әгъзасына 18 кв.метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы күләмендә билгеләнә торган торак урыны мәйданының хисап нормасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында бер гражданга торак урынының гомуми мәйданы 18 кв.метр күләмендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын билгеләргә.

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак мәйданын бирү һәм хисап нормасын билгеләү турында» 2008 елның 24 апрелендәге 166 нчы номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Р.И.Гариповка йөкләргә.

Җитәкче                                        И.И.Габдулхаев